ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

8 декабрь, 2022 ел № 18/9

Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә өстенлекле социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясы 8 өлеше нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/15, 2016 елның 18 маендагы 8/6, 2016 елның 8 июлендәге 9/11, 2020 елның 28 маендагы 39/7, 2020 елның 29 декабрендәге 4/6, 2022 елның 22 августындагы 16/11, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/9 номерлы Карарлары редакциясендә), 25.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«25.1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының алгарышлы үсеш территориясен үстерү бүлеге;».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ